ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
23.01.2020

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 90

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын Зеленодольск муниципаль районы территорияләренә беркетү турында

Төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем алуга гражданнарның конституциячел хокукларын тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетына яңа торак йортлар файдалануга кертелүгә бәйле рәвештә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гомуми белем бирү оешмаларын кушымта нигезендә Зеленодольск муниципаль районы территорияләренә беркетергә.
2. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү турында» 2019 елның 30 гыйнварындагы 220 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында» 2019 елның 13 мартындагы 632 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 01.02.2020 елдан үз көченә керә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми .http://pravo.tatarstan.ru)порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru мәгълүмати сайтында . урнаштырырга